ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03 08 2021 г. № 702

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 7 декабрендә кабул ителгән 1031 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә (оешмаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү (балалар бакчалары)» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 1491 номерлы карарына таянып, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 7 декабрендә кабул ителгән 1031 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә (оешмаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү (балалар бакчалары)» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.11 пунктында:

өченче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон» («РФ законнары җыелмасы», 27.11.1995, № 48, 4563 ст.);

егерме икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»2020 елның 31 июлендәге 373 номерлы боерыгы»;

«Муниципаль хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгеләүче норматив акт» баганасының 2.1, 2.3, 2.5, 2.8 пунктларында «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы боерыгы» сүзләрен «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2020 елның 31 июлендәге 373 номерлы боерыгы» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хезмәт алу өчен баланың ата-аналары (законлы вәкилләре) түбәндәге документлар тапшыралар:

- баланың ата-анасының (законлы вәкиленең) шәхесен таныклаучы документ яисә чит ил гражданы яисә Россия Федерациясендә гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документ;

- гариза (кәгазь чыганакта һәм (яки) электрон формада (тиешле мәгълүматларны интерактив формага кертү юлы белән тутырыла);

- психологик-медик-педагогик комиссиянең документы (кирәк булганда);

- сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемдә укуга ихтыяҗны раслаучы документ (кирәк булганда).

Исәпкә кую өчен баланың ата-аналары (законлы вәкилләре) күрсәтергә хокуклы:

- опеканы билгеләүне раслаучы документ (кирәк булганда);

- гражданнарның аерым категорияләренә һәм аларның гаиләләренә ярдәм итүнең махсус чараларына (гарантияләренә) хокук булуны раслаучы документ (кирәк булганда);

- Россия Федерациясе территориясендә бирелгән баланың туу турында таныклыгы.

Чит ил гражданнары яки гражданлыгы булмаган затлар булган баланың ата-аналары (законлы вәкилләре) баланың шәхесен таныклаучы һәм бала хокукларын тәкъдим итүнең законлылыгын раслаучы документны, шулай ук мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясендә булу хокукын раслаучы документны өстәмә рәвештә тапшыралар. Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар барлык документларны рус телендә яки расланган рус теленә тәрҗемә белән бергә тапшыралар.

Оешмага керү өчен баланың ата-аналары (законлы вәкилләре) күрсәтергә хокуклы:

- Россия Федерациясе территориясендә бирелгән баланың туу турында таныклыгы

- яшәү урыны яки беркетелгән территориядә тору урыны буенча баланы теркәү турында таныклык. Яшәү урыны яки беркетелгән территориядә тору урыны буенча баланың теркәү таныклыгы булмаган очракта, баланың ата-анасы (законлы вәкиле) баланың тору урыны, фактта яшәү урыны турында белешмәләре булган документ тапшыра.

Баланы оешмага кертү өчен ата-аналар (законлы вәкилләр) медицина бәяләмәсен күрсәтәләр.

2. Баланы исәпкә алу һәм (яки) баланы кабул итү өчен гаризада ата-ана (законлы вәкилләр) тарафыннан түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

- баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булганда);
- баланың туу датасы;
- баланың туу турында таныклыгы реквизитлары;
- баланың яшәү урыны (тору урыны, фактта яшәү урыны);
- баланың әти – әнисенең (законлы вәкилләренең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булганда);
- опека билгеләүне раслаучы документ реквизитлары (булганда);
- баланың ата-анасының (законлы вәкиленең) шәхесен таныклаучы документ реквизитлары;
- электрон почта адресы, баланың әти-әнисе (законлы вәкилләре) телефон номеры (булганда);
- Россия Федерациясе халыклары телләреннән белем алу телен, туган телне сайлап алу турында, шул исәптән туган тел буларак рус телен;
- мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган белем бирү программасы буенча баланы укытуга һәм (яки) инвалид баланы инвалидны реабилитацияләүнең индивидуаль программасы нигезендә укыту һәм тәрбияләүне оештыру өчен махсус шартлар тудыруга мохтаҗлык турында (булган очракта);
- мәктәпкәчә төркем юнәлеше турында;
- укырга кабул итүнең теләгән датасы турында.

Гаризада баланың ата-аналарына (законлы вәкилләргә) җибәрү өчен өстәмә рәвештә кабул итү өчен сайланган оешмалар турында һәм аерым категория гражданнарга һәм аларның гаиләләренә (кирәк булганда) ярдәм итүнең махсус чараларына хокук (гарантияләр) турында белешмәләр күрсәтелә.

Баланың бер гаиләдә яшәүче һәм аның белән уртак яшәү урыны булган, ата-ана (законлы вәкил) сайлаган оешмада белем алучы абый-энеләре һәм (яки) апа-сеңелләре булганда, баланы кабул итү өчен гаризада өстәмә рәвештә аның әти - әнисе (законлы вәкилләре) абый-энеләре һәм (яки) апа-сеңелләренең фамилия(ләр)сен, исем(нәр)ен, атасының итсем(нәр)ен (соңгысы – булганда) күрсәтә.

3. Баланы исәпкә алу өчен гариза һәм кушып бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысуллардан бирелергә (җибәрелергә) мөмкин:

- 64-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә һәм кәгазь чыганакта;
- 64-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә имзаланган (расланган) электрон формада бердәм портал һәм (яки) Республика порталы аша.

Күпфункцияле үзәк һәм җирле үзидарә органнары аша муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гаризалар һәм документлар кабул итү.

Оешмага керү өчен гариза һәм кушып бирелә торган документлар 64-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (расланган)

электрон документлар рәвешендә һәм (яки) кәгазь чыганакта муниципаль хезмәтне гамәлгә ашыру кысаларында АМС ЭББ аша направление алынган оешмага бирелә.

4. Гариза һәм кирәкле документларны Бердәм портал һәм (яки) республика порталы аша җибәргәндә, гариза бирүче гади электрон имза белән имзалый.

Соратуны Бердәм портал һәм (яки) республика порталы аша бирү өчен гариза бирүче документларның электрон үрнәкләрен яисә әлеге пункт таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган документларны тапшыра.

2.5.1 пунктчасында күрсәтелгән документлар (психологик-медик-педагогик комиссия документы, сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемдә белем алу ихтыяҗын раслаучы документ, аерым категория гражданнарга һәм аларның гаиләләренә махсус ярдәм чараларына хокук булуны раслаучы документ) мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән раслана.».

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.6. пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гаризага гариза бирүче тарафыннан кертелгән бала турында мәгълүматлар ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында автомат рәвештә раслана.»

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.14. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда һәм урыннарда башкарыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озатып йөрүче этләрне файдаланучыларга, бинадан, урыннардан һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү буенча түбәндәге чаралар гамәлгә ашырыла:

- бинага һәм урыннарга, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә тоткарлыксыз керү өчен шартлар;
- элемтә һәм мәгълүмат чараларыннан тоткарлыксыз файдалану өчен шартлар;
- объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу, транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү, шул исәптән кресло-коляска кулланып, мөмкинлеге;
- күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләре нык бозылган инвалидларны озатып бару һәм биналарда һәм урыннарда аларга ярдәм күрсәтү;
- тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, инвалидларның биналарга, урыннарга, хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз үтеп керә алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат чыганакларын тиешенчә урнаштыру;
- инвалидлар өчен кирәкле тавышлы һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайльнең рельефлы-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;
- аны махсус укытуны раслый торган һәм халыкны социаль яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм тормышка ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу

функцияләрен гамәлгә ашыручы башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан билгеләнә торган форма һәм тәртиптә бирелә торган документ булганда, бинага һәм урыннарга озатып йөрүче этне кертү;

- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтү алуга комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгуда инвалидларга ярдәм күрсәтү.»;

«Муниципаль хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгеләүче норматив акт» баганасының 2.14. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон»;

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.15. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда һәм урыннарда башкарыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озатып йөрүче этләрне файдаланучыларга, бинадан, урыннардан һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү буенча түбәндәге чаралар гамәлгә ашырыла:

- бинага һәм урыннарга, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә тоткарлыксыз керү өчен шартлар;

- элемтә һәм мәгълүмат чараларыннан тоткарлыксыз файдалану өчен шартлар;

- объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу, транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү, шул исәптән кресло-коляска кулланып, мөмкинлеге;

- күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләре нык бозылган инвалидларны озатып бару һәм биналарда һәм урыннарда аларга ярдәм күрсәтү;

- тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, инвалидларның биналарга, урыннарга, хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз үтеп керә алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат чыганакларын тиешенчә урнаштыру;

- инвалидлар өчен кирәкле тавышлы һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайльнең рельефлынокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

- аны махсус укытуны раслый торган һәм халыкны социаль яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм тормышка ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан билгеләнә торган форма һәм тәртиптә бирелә торган документ булганда, бинага һәм урыннарга озатып йөрүче этне кертү;

- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтү алуга комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгуда инвалидларга ярдәм күрсәтү.».

«Муниципаль хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгеләүче норматив акт» баганасының 2.15. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон».

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны басма матбугатта һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – Мәгариф идарәсе җитәкчесе Р.М. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов